# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Бюджет кодексына
үзгәреш кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 7 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

2004 елның 29 маендагы 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12), түбәндәге эчтәлекле $55^2$ статья өстәп, үзгәреш кертергә:

"$55^2$ статья. **Татарстан Республикасы Юллар фонды**

1. Татарстан Республикасы Юллар фонды – региональ яисә муниципальара әһәмиятле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү максатларында кулланылырга тиешле Татарстан Республикасы бюджеты чараларының бер өлеше.
2. Татарстан Республикасы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләре күләме Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең түбәндәгеләрдән фаразлана торган күләменнән кимрәк булмаган күләмдә чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән раслана:

Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган автомобиль бензинына, турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, дизельле һәм карбюраторлы (инжекторлы) двигательләр өчен мотор майларына Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле акцизлардан;

транспорт салымыннан;

региональ яисә муниципальара әһәмиятле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан субсидияләрдән;

региональ яисә муниципальара әһәмиятле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә физик һәм юридик затларның кире кайтарылмый торган кертемнәреннән, шул исәптән ирекле иганәләреннән.

3. Татарстан Республикасы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләрен булдыру һәм куллану тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы Юллар фондының агымдагы финанс елында кулланылмаган бюджет ассигнованиеләре чираттагы финанс елында Татарстан Республикасы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 1 августы
№ 60-ТРЗ